ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**30.12.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3440**

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү бәясенең чик күләмнәре турында

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балансланган кайнар ризык белән тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елның 12 гыйнварыннан Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү бәясенең чик күләмнәрен түбәндәгечә билгеләргә:

- башлангыч сыйныф укучылары өчен иртәнге кайнар аш 55 сум 55 тиен, шулардан 55 сум 55 тиен-субсидия;
- өлкән сыйныф укучылары өчен иртәнге кайнар аш 71 сум 64 тиен, шуның 63 сум 34 тиен-ата-аналар түләве, 8 сум 30 тиен-субсидия;
- өлкән сыйныф укучылары өчен төшке аш 71 сум 64 тиен, шуның 63 сум 34 тиен - ата-аналар түләве, 8 сум 30 тиен-субсидия;
- югары сыйныф укучылары өчен ирекле сайлау меню бәясе 87 сум 32 тиен, шуларның 79 сум 02 тиен - ата-аналар түләве, 8 сум 30 тиен - субсидия.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 декабрендәге «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү бәясенең чик күләмнәре турында» 2612 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы- җитәкчесе урынбасары Р.В. Афанасьевага йөкләргә. .

Җитәкче И. Р. Ганиев